Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2019 елның 30 декабре № 131

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә “муниципаль хезмәт турында " гы 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, теркәлүне раслый торган документ;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Барыш авылы, Үзәк урам, 15нче йорт;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кыртапа авылы, Мәктәп урамы,10 нчы йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Советы рәисе И.Р.Җиһаншин